| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
|---|---|
| 2015 ел, 2 июль | № 481 |

г. Казань

Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Свияжск (Зөя) авылы адресы буенча урнашкан «Свияжск (Зөя) утрау-шәһәре» истәлекле урыны» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен, әлеге зоналар чикләрендә җирләрдән файдалану режимнарын һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында» 2002 ел, 25 июнь, 73-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 ел, 26 апрель, 315 нче карары белән расланган Мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау зоналары турында нигезләмә, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 ел, 1 апрель, 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Свияжск (Зөя) авылы адресы буенча урнашкан «Свияжск (Зөя) утрау-шәһәре» истәлекле урыны» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен;

Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Свияжск (Зөя) авылы адресы буенча урнашкан «Свияжск (Зөя) утрау-шәһәре» истәлекле урыны» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрендә җирләрдән файдалану режимнарын һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Свияжск (Зөя) авылы адресы буенча урнашкан «Свияжск (Зөя) утрау-шәһәре» истәлекле урыны» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләре турында белешмәләрне Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) бердәм дәүләт реестрына кертү өчен 2015 елның 1 октябренә кадәр Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгына материаллар җибәрергә.

3. Зеленодольск һәм Югары Ослан муниципаль районнары, «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Свияжск (Зөя) авылы адресы буенча урнашкан «Свияжск (Зөя) утрау-шәһәре» истәлекле урыны» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын саклау зоналарында һәм аларның чикләрендә «Свияжск (Зөя) утрау-шәһәре» истәлекле урыны» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясеннән күз күреме чикләрендә әйләнә-тирә ландшафтның үзгәрмәвен тәэмин иткән шәһәр төзү регламентларын билгеләргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\481.docx